КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 август г.Казань № 641

Германия Федератив Республикасында Татарстан Республикасының Сәүдә-икътисади вәкиллеген гамәлгә кую турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Германия Федератив Республикасында Татарстан Республикасының Сәүдә-икътисади вәкиллеген гамәлгә куярга.

2. Карарга теркәлгән Германия Федератив Республикасында Татарстан Республикасының Сәүдә-икътисади вәкиллеге турында нигезләмәне расларга.

3. Гатауллин Таһир Мияссәр улын Германия Федератив Республикасында Татарстан Республикасының Сәүдә-икътисадый вәкиле итеп билгеләп куярга.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Германия Федератив Республикасында Татарстан Республикасының Сәүдә-икътисад вәкиллеге эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү турындагы тәкъдимнәрне кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 3 август, 641 нче
карары белән расланды

Германия Федератив Республикасында Татарстан Республикасының Сәүдә-икътисади вәкиллеге турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Германия Федератив Республикасында Татарстан Республикасының Сәүдә-икътисадый вәкиллеге (алга таба – Вәкиллек) эшчәнлеге нигезләрен, аның хокукый статусын, максатын, бурычларын һәм функцияләрен билгели.

1.2. Вәкиллек Татарстан Республикасы Президенты кушуы буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә куела.

1.3. Вәкиллек үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, Германия Федератив Республикасы законнары, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Германия Федератив Республикасы арасында шартнамәләр һәм килешүләргә, әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Вәкиллек дипломатик вәкиллек статусына ия түгел, аңа консуллык яки дипломатик функцияләр йөкләнә алмый. Вәкиллек хезмәткәрләре дипломатик өстенлекләр һәм иммунитетлардан файдаланмыйлар.

1.5. Вәкиллек – юридик зат, Татарстан Республикасының Дәүләт Гербы рәсеме һәм үзенең исеме белән мөһер, аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле билгеләнгән үрнәктәге штамп һәм бланклары бар.

1.6. Вәкиллек Россия Федерациясе һәм Германия Федератив Республикасы законнары нигезендә банкларда счетларны ача һәм яба.

1.7. Вәкиллек Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм башка чыганаклардан бүлеп бирелгән акчалар хисабына оператив идарә итү хокукында яисә сатып алынган мөлкәтне алырга яисә аннан башка ысул белән файдаланырга хокуклы түгел.

1.8. Вәкиллекнең урнашу урыны: Лейпциг шәһәре, Саксония федераль җире, Германия Федератив Республикасы.

2. Вәкиллекнең максаты, бурычлары, функцияләре

2.1. Вәкиллекнең максаты – Татарстан Республикасы һәм Германия Федератив Республикасы арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәдәни һәм гуманитар элемтәләрне һәм багланышларны билгеләү, үстерү һәм киңәйтүгә ярдәм итү.

2.2. Вәкиллекнең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

сәүдә, финанс-кредит эшчәнлеге, инвестицияләр, фәнни һәм мәдәни элемтәләр, алмашулар, халыкара туризм һәм Россия Федерациясе компетенциясенә кагылмаган

башка икътисадый һәм гуманитар эшчәнлек төрләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен тәкъдим итү;

Татарстан Республикасы территориясендә һәм Германия Федератив Республикасы территориясендә теркәлгән юридик затларга сәүдә, фәнни-техник, икътисадый һәм гуманитар хезмәттәшлек өлкәсендә ярдәм итү.

2.3. Вәкиллекнең функцияләре булып тора:

Германия Федератив Республикасы базарында Татарстан Республикасының нәтиҗәле һәм үзара файдалы тышкы икътисадый элемтәләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны җыю, анализлау һәм тапшыру;

Татарстан Республикасының икътисадый, социаль, мәдәни һәм гуманитар өлкәләренә Германия Федератив Республикасыннан инвестицияләр җәлеп итүгә ярдәм итү;

Германия Федератив Республикасы базарларына Татарстан Республикасы предприятиеләре продукциясен этәрүгә ярдәм итү;

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән юридик затларга Германия Федератив Республикасы базарын өйрәнүдә ярдәм итү;

Татарстан Республикасы һәм Германия Федератив Республикасы территорияләрендә теркәлгән юридик затларга турыдан-туры хуҗалык элемтәләрен урнаштыруга, уртак предприятиеләр булдыруга һәм икътисадый, финанс һәм гуманитар өлкәләрдә хезмәттәшлекнең башка мөмкин булган уртак формаларын булдыруга ярдәм итү;

Татарстан Республикасының фәнни үзәкләре, учреждениеләре, институтлары, университетлары һәм Германия Федератив Республикасының фәнни, уку үзәкләре һәм университетлары арасында элемтәләр урнашуга һәм галимнәр, белгечләр һәм студентлар алмашуны оештыруга ярдәм итү;

хокукый, методик, мәгълүмати-реклама, консультация һәм башка характердагы мәсьәләләр буенча сәүдә-икътисадый, мәдәни, гуманитар, спорт һәм башка элемтәләрдә катнашучыларга ярдәм итү;

Татарстан Республикасы белән Германия Федератив Республикасы арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәдәни һәм гуманитар хезмәттәшлекне үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Германия Федератив Республикасында партнерлар белән сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәдәни һәм гуманитар хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча сөйләшүләр уздыру;

хезмәттәшлекнең төрле мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы делегацияләренең Германия Федератив Республикасына сәфәрләрен әзерләү һәм оештыру;

Германия Федератив Республикасында татар диаспорасы белән элемтәләр урнаштыру һәм үстерү;

Вәкиллекнең максатларына һәм бурычларына туры килә торган башка функцияләре.

### 3. Вәкиллек җитәкчесенең хокуклары һәм бурычлары

3.1. Вәкиллек җитәкчесе Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлек белән идарә итүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле органы тәкъдиме буенча өч елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә.

3.2. Вәкиллек җитәкчесе вәкиллекнең хуҗалык һәм финанс эшчәнлеге өчен шәхси җавап тота.

3.3. Вәкиллек Җитәкчесе:

Германия Федератив Республикасының дәүләт органнары, юридик затлар һәм гражданнары белән мөнәсәбәтләрдә Вәкиллекне тәкъдим итә;

Ввәкиллек хезмәткәрләре тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле боерыклар һәм күрсәтмәләр чыгара;

Вәкиллек эшчәнлегенә кагылышлы финанс, хисап документларын һәм башка документларны имзалый, ышанычнамәләр бирә, вәкиллекнең исәп-хисап һәм башка счетларын ача;

Вәкиллек хезмәткәрләрен эшкә ала һәм эштән азат итә;

ел саен Вәкиллек эшчәнлеге турында хисапны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдим итә

## 4. Вәкиллекнең финанс эшчәнлеге һәм мөлкәте

4.1. Вәкиллек эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты һәм законнарга каршы килми торган башка чыганаклар хисабына гамәлгә ашырыла.

4.2. Вәкиллекнең чыгымнар сметасы Татарстан Республикасы Президенты белән килешенеп Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4.3. Вәкиллекнең мөлкәте оператив идарә итү хокукында аңа беркетелгән, Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган биналарны, корылмаларны, бүлмәләрне, җиһазларны, транспорт чараларын һәм куелган бурычларны тормышка ашыру өчен кирәкле башка мөлкәтне, шулай ук Вәкиллек тарафыннан бюджеттан тыш чыганаклардан алынган мөлкәтне тәшкил итә.

## 5. Вәкиллек җитәкчелеге

5.1. Вәкиллек Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына буйсына.

5.2. Вәкиллек эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне һәм аның эшчәнлеген тикшереп торуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләр биргән Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлек белән идарә итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы башкара.

5.3. Вәкиллекнең структурасы һәм штат расписаниесе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләр биргән Татарстан Республикасының тышкы икътисадый эшчәнлек белән идарә итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5.4. Вәкиллек Германия Федератив Республикасында эшчәнлек алып бара торган Татарстан Республикасы предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре йөкләмәләр буенча җавап бирми, ә алар Вәкиллек йөкләмәләр буенча җавап бирми.

## 6. Вәкиллек эшчәнлеген туктату

6.1. Вәкиллекнең эшчәнлеге туктатылу Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы белән консультациядән соң Татарстан Республикасы Президенты карары белән гамәлгә ашырыла.

6.2. Вәкиллекне бетергәннән соң калган мөлкәт Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә бүленә.

---